**ГЛАВА**
**Старокакерлинского**
**сельского поселения**
**Дрожжановского муниципального**
**района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Иске Кәкерле**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**422476, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Старые Какерли, ул. Советская, д.51**
**тел. (84375) 30-1-35, 30-2-35, факс. 30-2-35**

---

Постановление Боерык

2015 елның 8 декабре г. № 19

Иске Кәкерле авыл җирлегендә янгынга

каршы махсус режим билгеләү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 7 декабрендәге 481 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле районы КЧС 2015 елның 1 декабрендәге 11-15р номерлы Карарын үтәү йөзеннән, Иске Кәкерле авыл җирлеге территориясендә Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү максатларында карар бирәм:

1.2015 елның 15 декабреннән 2016 елның 10 гыйнварына кадәр Иске Кәкерле авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштыру;
2.Иске Кәкерле авылының Тау урамында урнашкан 17 нче йорттан 50 м һәм Татар Төкесе авылының Колхоз урамы буенча 1 нче йорттан 40 м пиротехника әйберләрен куллану урыны итеп билгеләргә;

3.Ирекле янгын сагы әгъзаларының һәм ДНД әгъзаларының дежурлыгын оештырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Кәкерле Авыл Җирлеге Башлыгы: С. А. Хөсәенов